# ПОЧМАКТА ТАБИГЫЙ МАТЕРИАЛЛАР

Балаларга иҗат итү өчен балчык, төшләр, күркәләр, чикләвек, ярмалар бар. Аларны кулланып эшләгән кул эшләре урнаштырылган.



Табигый материаллар



“Башак” әкиятенә иллюстрация







Балчыктан сыннар, картина.



Саламнан чәчәк



Төшләрдән букет



Фанерадан бобр

# КҮЗӘТҮЛӘР

Табигать почмагында үсентеләрне күзәтәбез. Нәтиҗәләрен язып барабыз. Күзәтүләр балаларга табигатьтәге бәйләнешләрне аңларга ярдәм итә.



Шомырт ботагы: яфрак, чәчәк бөреләре.



Кыяр үсентесе.



Борчак үсентесе.



Борыч үсентесе.



“Коры аквариум”



Попугай белән “сөйләшәбез”.

# Табигать – серле хәзинә.

Без балаларга экологик тәрбия бирүгә зур игътибар бирәбез. Югары нәтиҗәләргә ирешү өчен табигать почмагын тиешенчә җиһазлаудан башладык. Балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән гөлләрне сайладык, эш кораллары булдырдык, үсентеләр утырттык.

Почмагыбыздагы “Туган якны өйрәнәбез” стенды һәрвакыт “эшләп” тора.

-көн дә һава торышын билгелибез.

-числоны, айны күрсәтәбез.

-ел фасылын чагылдырган рәсемнәр куябыз.

-табигатьне саклауга багышланган рәсемнәр ясап куйдык.Һ.б.

Табигать белән таныштыру һәм экологик тәрбия бирү түбәндәге юнәлешләрдә алып барыла: күзәтү, шөгыльләр, хезмәт,тәҗрибәләр,әдәби әсәрләр уку, дидактик уеннар уйнау,табигый материаллар кулланып иҗат итү,экскурсияләр.

Тере табигатьнең бер-берсен тулыландырып экосистема ясаганын төшендерү өстендә эшлибез. Экосистема-ул бер челтәр, әгәр челтәрдәге бер җан иясе бетсә, башкаларын да шундый һәлакәткә китерергә мөмкин.Табигатьтәге һәр нәрсәнең үз урыны, әһәмияте бар.

Табигать почмагындагы эшчәнлеккә ата-аналарны да тартабыз: үсентеләр, гөлләр алып киләләр.

Табигатьнең байлыгы чиксез-файдалана белергә, матурлыгы чиксез күрә белергә генә кирәк. Балаларыбызга кечкенәдән менә шуны төшендерә алсак, үзебезне чолгап алган табигатебез өчен күңелебез тыныч булыр.











Ылыслардан “керпеләр”

Каурыйдан чәчәкләр

Ярмалардан ваза







Төшләрдән панно

Балчыктан әтәч

Күркәләрдән кешеләр







Мамык кар бабайлар

Кипкән яфраклардан открытка

Камырдан сыннар